Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы карары

2021 елның 31 мае №26

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советының 2013 елның 1 ноябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советының 2013 елның 1 ноябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенәтүбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

«3.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе И.А.Зиновьев